# Казаным - башкалам





***И Казан! Дәртле Казан!***
***Моңлы Казан! Нурлы Казан!***

*Габдулла Тукай*

# *И Казан, серле Казан!*

*Сезнең Казанда булганыгыз бармы? Казанның берсеннән – берсе матур йортлары, урамнары, истәлекле урыннары турында ниләр беләсез? Әйдәгез, Казан буйлап сәяхәткә чыгабыз? Кузгалдык.*








*Казан - Идел буе регионында иң зур мәдәни-сәнгать үзәкләренең берсе. Ул-Татарстанның башкаласы. Шәһәрдә җитмеш җиде милләттән булган 1 миллионнан артык кеше яши.*

*Шәһәр 7 районга бүленгән: Вахитов, Совет, Киров, Мәскәү, Идел буе, Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнары.*



# *Дәүләт символлары*












Шәһәрнең үзәк өлешендә, Казансу елгасы ярында, тарихи һәйкәл – Кремль балкып тора. Кремль 4,5м киңлегендәге ак таш стена белән әйләндереп алынган. Биредә Президент Сарае, Казан ханлыгыннан сакланып калган уникаль архитектура истәлеге – Сөембикә манарасы һәм Благовещение соборы урнашкан.






# *Кремльгә сәяхәтне дәвам итәбез.*



- 1.Күрше район.
- 2. Татар халкының чисталык билгесе.
- 3. Татарстанда иң зур елга.
- 4. Укытучылар өчен нәшер ителүче журнал.
- 5.Татар халкының милли бәйрәме.
- 6. Казандагы район исеме.
- 7. Казан шәһәрендә күл исеме.
- 8. Милли татар ризыгы.



Әлбәттә, Кремльдәге иң мәһабәт бина - Сөембикә манарасы. Җиде катлы бу бина әллә кайлардан ук күренеп тора. Ислам дине өйрәтүе буенча, күк җиде каттан тора. Җиде катлы бу манара да күкне җиденче катына омтылганлыкны раслап тора. Аның биеклеге 58 метр. Ул нигезе тигез булмау сәбәпле, көнчыгышка авышкан. Соңгы елларда, авышуны туктату өчен, нигезне ныгыту эшләре алып барылды.

Сөембикә манарасын татар халкында Биек манара, Бөек манара, Хан мәчете дип тә йөрткәннәр






# *Сөембикә манарасы*

*Атаклы Сөембикә манарасы Кремль эчендә урнашкан. Әлеге манара хакында халык күңелендә төрле риваятьләр саклана. Чынлап та, әлеге биек манара нигә "Сөембикә" дип аталган соң?*

*Бервакыт Мәскәү патшасы Сөембикәнең (ул Казан ханбикәсе була) рәсемен күрә дә гашыйк була. Илчеләрен җибәрә инде бу хәзер Казанга, Сөембикә янына, үзенә кияүгә чыгарга сорап. Сөембикә моңа риза булмый. Шуннан Мәскәү патшасы, ачуы килеп: "Үз теләгең белән чыкмасаң, мин сине сугышып алам", - ди дә Казан ханлыгына каршы сугыш ача. Җиде ел камап торганнан соң, крепость стеналарын ваттырып, Казан шәһәрен ала бу. Сөембикә патшаның җиңүен күргәч, ире күмелгән мәчетнең манарасына менә дә аска ташлана. Менә шуннан соң инде Хан мәчетен "Сөембикә манарасы" дип атый башлыйлар.*



# Тукай музее



Габдулла Тукай музее (элеккеге Шамил йорты) 1903 елда тәзелгән. Бина сәүдәгәр Апаков акчасына аның кызы өчен салына.

Хәзерге көндә бу бинада татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай музее урнашкан. Биредә аның тормышын, иҗатын һәм үзе яшәгән чорны чагылдырган экспонатлар тупланган.



# Сынлы сәнгать музее



*Сынлы сәнгать музее XIX гасырның 60 нчы елларында оеша. Бүгенге көндә музейда зур эш башкарыла. Фәнни хезмәткәрләр биредә сәнгать әсәрләрен өйрәнәләр, яңаларын эзләп табалар.*

*Музей залларыннан үтү еллар, гасырлар буйлап сәяхәт итүгә тиң.*



# Казан дәүләт университеты



Казан Дәүләт Университеты – башкалабызның горурлыгы. Аңа 1804 елда нигез салына. Әлеге уку йорты Идел буе халыкларының мәдәният һәм мәгариф үсешенә зур йогынты ясый.

Казан университеты бүгенге көндә дә Россиядә иң данлыклы уку йортлары рәтендә.






# Сүзлек өстендә эш

Төп бина- главное здание

Атаклы-знаменитый

Шәрык телләре- восточные языки

Төбәк- край, регион

Горурлык - гордость





# 1 нче төркемгә бирем.

1.Вокзалдан шәһәр үзәгенә 7 нче троллейбус, 2 нче трамвай белән барып була.
2. Казан университеты Россиядәге иң борынгы университетларның берсе.



2 нче төркемгә бирем.

1.Дәүләт музее Кремль янында урнашкан.

2. Пушкин һәйкәле опера һәм балет театры янында.





# 3 нче төркемгә бирем.

1. Министрлар кабинеты Ирек мәйданында урнашкан.
2. Казан елдан ел үсә,матурая.



# Белемнәрне тикшерү.

1. Татарстанның башкаласы?
2.Гимнның авторы?
3. Казан Кремле янында нинди мәчет бар?
4. Казан дәүләт университеты ничәнче елда ачылган?
5. Г.Камал исемендәге дәүләт акдемия театры янында нинди күл бар?
6. Татарстан,Россия флагларында нинди төсләр бар?



# *Мәкаль*

*Үз илем- алтын ………*



# Сүзләрне тәрҗемә итегез

Древний

Просторный

Поэт

Река

Крылатый




# сүзлек

- Древний- **б**орынгы
- Просторный- **и**ркен
- Поэт- **ш**агыйрь
- Река – **е**лга
- Крылатый- **к**анатлы

Үз илем – алтын бишек.



# Мәңге яшь бул,
# Казаным!



# Кулланылган материал:

1.“Казан-сихри башкалам” London WS 2H 8HJ.

2. “Сөембикә”, “Ялкын”, “Салават күпере” журналлары.

Презентация сыйныфтан тыш чараларда һәм рус сыйныфларында дәресләрдә куллану өчен тәкъдим ителә.

Эшләде: Казан шәһәре Совет районы 159 нчы лицейның икенче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Исмәгыйлова Гөлнур Наил кызы
2010 ел



# Г. Камал театры



Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,

Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.


Театр яктылыкка, нурга илтә,

Кире юлга җибәрми, унга илтә.

*Театр – милләт язмышының һич тутыкмас көзгесе ул. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры да күп еллар буе шул дәрәҗәдә бурычын уңышлы үти. Аның Мәскәүдә дә, Петербургта да, чит илләрдә дә абруе хаклы рәвештә арта бара.*



# *Кол Шәриф мәчете*



*Казан Кремле (кирмән) эчендәге биш таш мәчетнең берсе һәм иң зурысы, иң атаклысы Кол Шәриф исемен йөрткән. Риваятьләргә караганда, мәчет искиткеч матур, бай итеп бизәлгән булган.*

*Җөмһүриятебезнең бәйсезлеге турында декларация кабул ителгәч, Кол Шәриф мәчетен торгызу турында мәсьәлә күтәрелә. Мәчетне элекке урыннан читтәрәк (элек ул Благовещение чиркәве урынында булган) салалар.*

*Проектны атаклы татар архитекторы Искәндәр Сәйфуллин төзи.*

